СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Карла Маркса, д.2, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 2 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

13 январь 2025 ел — № 1-43

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 1-32 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 89 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге
башлыгы, авыл җирлеге
Советы рәисе /С.Н.Степанов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге
Советының
13.01. 2025 ел, № 1-43
карарына Кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының
«Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Уставына кертелүче үзгәрешләр

1. 1 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
«Муниципаль берәмлекнең кыскартылган исеме – «Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге».

2. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

3. Уставның 19 статьясындагы 5 пунктының 2 абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм $9^2$ пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

4. 29 статьяның 11, 12 өлешләрендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министрының) " сүзләрен төшереп калдырырга;

5. 41 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:
«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;

6. 41 статьяның 5 өлешендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министрының) " сүзләрен төшереп калдырырга;

7. 44 статьяның 5.1 өлешендәге 12 пунктының «б» пунктчасында "(Татарстан Республикасы Премьер-министры) " сүзләрен төшереп калдырырга;

8. 46 статьяның 8.1 өлешендәге 12 пунктының «б» пунктчасында "(Татарстан Республикасы Премьер-министры) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

9. 47 статьяның 4 өлешендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министрының) " сүзләрен төшереп калдырырга;

10. 50 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыра.»;

11. 75 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:
«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар».